**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2023-2024 нче уку елы**
**9 нчы сыйныф**

**Максималь балл –62**

## I. ТЕСТ (20 балл)

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **2** | **4** | **1** | **4** | **1** | **1** | **4** | **2** | **укыган** | **иярчен синтетик вакыт** |

**III. Теоретик бирем.**
Җөмләнең иярчен кисәкләре турында языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. **(6 балл)**
Укучы мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, мисаллар белән дәлилләгәндә, биремгә иң югары балл куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны киметелә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

## III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.

1. Сүзләр һәм аларның ясалыш ысулларын тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) көнбагыш | 1) тамыр сүз |
| Ә) пыяла | 2) ясалма сүз |
| Б) сиртмә койрык | 3) саф кушма сүз |
| В) тозсыз | 4) тезмә сүз |
| Г) әйлән-бәйлән | 5) парлы |

**Җавап : 31425**

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җәя эчендәге сүзләрнең дөресен сайлап, астына сызыгыз. **(4 балл)**

Мин яр өстеннән елгага карап торам. Ык тын гына (бара / **ага** / шаулый). Баеп баручы кояш, елга өстеннән нәрсәдер эзләгәндәй, күләгәләр арасыннан үрелеп-үрелеп карый да, кемнәндер оялган кебек, агач (башына / **арасына** / өстенә) кереп яшеренә. Елга тын. Инде ташу (ашкан / барган / **киткән**). Су кимүгә таба (китә / **бара** / җитә). Шуңа күрә елга, язгы ташу вакытындагыдай, биек ярлар өстенә бозлар түкерми, ул, йөгәнгә яңа гына өйрәтелгән ярсу тай кебек, күбеккә батканчы чапкан-чапкан да, буйсынып, тынып калган. (*Ф. Яруллиннан*)

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл)**

Укытучы

Уч төбенә куеп Җирне гүя,
Бүгенгесен аның, үткәнен
Күрсәтте ул безгә
Урап кайттык
Күренмәгән илләр үтәли.

Аяз дөнья, кешелек бәхете өчен
Көрәшергә безне өндәде <....>

- Яратыгыз Җирне! – диде һаман,
- Мине яратыгыз! – димәде. (*Р. Гаташ*)

3. Шигырьнең икенче куплетындагы <....> тамгасы урынына куелырга тиешле тыныш билгесен языгыз **(2 балл)**
**ике нокта**
4. Беренче куплеттан капма-каршы мәгънәле сүзләрне күчереп языгыз. (**2 балл**)
Бүгенгесен - үткәнен
5. Шигырьдән ясалма исемне күчереп языгыз, мәгънәле кисәкләргә аерыгыз, шартлы билгеләр белән күрсәтегез, морфологик анализ ясагызэ (**3 балл**)
**Кеше – тамыр, -лек - сүз ясагыч кушымча, нигезе – кешелек. Кешелек – ясалма исем, уртаклык исеме, баш килештә, берлек санда.**

6. Ирен гармониясенә буйсынган сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл)**
төбенә, өчен

7. Шигырьнең беренче куплетыннан алмашлыкларны күчереп языгыз, төрләнешен аңлатыгыз . **(6 балл)**
Аның – иялек килеше, ул – баш килеш, безгә - юнәлеш килеше

8.“*Матурлык эштә күренә*” темасына 9-10 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)